**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2768**
**09.06.2020**

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасының «2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2019 елның 30 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләрне билгеләү турында» 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы карары, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 9 июнендәге
2768 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә
спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында (алга таба - оешмалар) эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура спорт оешмаларының хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләрне билгеләү турында» 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы карары белән расланган күләмнәрдә акчалата түләүләр бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Оешмалар хезмәткәрләренә - яшь белгечләренә акчалата түләүләр Татарстан Республикасы бюджетыннан Яр Чаллы шәһәре бюджетына керә торган башка бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.

3. Оешма хезмәткәре - яшь белгече дип, беренче тапкыр көндезге уку формасы буенча һөнәри белем бирү оешмасын, югары белем бирү программалары - бакалавриат, белгечлек, магистратура программалары буенча дәүләт аккредитациясе алган югары белем бирү оешмасын (алга таба - һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирү оешмасы) тәмамлаган һәм һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белем бирү оешмасын тәмамлаган елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча һөнәри белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе нигезендә хезмәт килешүе буенча физик культура буенча инструктор, педагог-оештыручы, педагог-психолог, физкультура-спорт оешмалары инструктор-методисты, адаптив физик культура буенча инструктор-методист, адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист, тренер, адаптив физик культура буенча тренер-укытучы, хореограф, тренировкалар процессы администраторы, адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы вазыйфаларына оешмага кабул ителгән 30 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданы танылa.

4. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә ул эшкә урнашкан айдан соң килә торган айның 1 числосыннан билгеләнә һәм, әлеге тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфада өзлексез эшләү шарты белән, аны билгеләү датасыннан башлап беренче өч ел дәвамында түләнә.

5. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүне билгеләү, туктату, озайту турындагы карар оешма боерыгы белән раслана.

6. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү түбәндәге чорга озайтыла:

1) Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш буенча хезмәт итү яки альтернатив граждан хезмәте узу;

2) йөклелек һәм бала табу буенча ял, өч яшькә җиткәнче бала карау буенча ял;

3) көндезге формада аспирантурада уку.

7. Хезмәткәр - яшь белгеч әлеге тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфа буенча башка оешмага күчкәндә, эштә 30 көннән дә артмаган өзеклек рөхсәт ителә.

8. Сан яки штат кыскартылу сәбәпле, хезмәткәр - яшь белгеч эштән киткәндә һәм әлеге тәртипнең 3 пунктында каралган вазыйфа буенча башка оешмага эшкә урнашканда, 60 көннән артмаган өзеклек рөхсәт ителә.

9. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

10. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә төп вазыйфа буенча һәм әлеге хезмәткәр - яшь белгеч тарафыннан бер үк вакытта 1 ставкадан да артмаган эчке ике эш башкару шартларында гамәлгә ашырыла торган вазыйфа буенча билгеләнә.

11. Хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times \frac{H_f}{H_n},$$

монда:

D - хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә күләме, сум;

P - хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә аена 1 111 сум күләмендә стимуллаштыручы өстәмә;

Hf - хезмәткәр - яшь белгеч тарафыннан эшләнгән сәгатьләрнең фактттагы саны, сәгать;

Hn - спорт резервын әзерләүче оешма хезмәткәрләренең хезмәт хакының база ставкасы өчен сәгать нормасы, сәгать.

12. Оешмалар ай саен, агымдагы елның 5 числосына кадәр, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсенә түбәндәге документларны тапшыралар:

1) әлеге тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру өчен акча бирү турында заявка;

2) әлеге тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча оешма хезмәткәрләре - яшь белгечләре реестры.

13. Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе әлеге тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән документларны, алар кергән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көнлек срокта карап тикшерә.

Оешма тарафыннан әлеге Тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын яки 12 пункт таләпләренә туры килми торган документлар тапшырылган очракта, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе гаризаны кире кайтара һәм кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, биш көн срокта оешмага хәбәр итә.

Оешма гаризаны кире кайтару турында белдерү кәгазен алган көннән башлап, әлеге тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, әлеге тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән документларны кабат тапшыра.

14. Оешманың хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга чыгымнарын финанс белән тәэмин итү әлеге максатлар өчен башка бюджетара трансфертлар бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Башка бюджетара трансфертлар Башкарма комитет һәм оешма арасында төзелгән килешү (алга таба - килешү) нигезендә бирелә.

Килешү әлеге тәртипнең 12 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылган көннән башлап 10 көн срокта төзелә.

15. Оешмалар физик культура һәм спорт идарәсенә, килешүдә каралган сроклар һәм форма нигезендә, хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыралар.

16. Агымдагы финанс елында оешма тарафыннан файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның калдыклары билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиеш.

17. Оешма тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылганда, Башкарма комитет физик культура һәм спорт идарәсенең язма таләбе нигезендә, тиешле таләп алынган көннән башлап 10 эш көне эчендә, башка бюджетара трансфертлар билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

18. Оешма тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү, шулай ук төзелгән килешүләрнең шартлары үтәлешен контрольдә тоту Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның финанс идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

19. Оешмалар хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирүне оешмалар тарафыннан билгеләнгән хезмәт хакын түләү срокларында тәэмин итәләр.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибенә
1 нче кушымта

«_____»_________ 20___ елга акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга акча бирү турында заявка
___________________________________________________________________________

| № т/б | Оешманың кыскача исеме | Хезмәткәрнең - яшь белгечнең Ф.И.А.и. | Били торган вазыйфасы | Эшкә кайчан керәште | Вазыйфада 3 ел эш срогы кайчан чыга | Ставкадагы эш күләме | Акчага ихтыяж, сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | айлык өстәмәгә, сум | иминият взносларын түләүгә, сум | түләү суммасы (8+9 графалар суммасы) |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 2 | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | |
| 4 | | | | | | | | | |

Директор

____________________/_________________/

м.у.

Татарстан Республикасы Яр Чаллы
шәһәрендә спорт резервын әзерләүне
гамәлгә ашыручы муниципаль
физкультура спорт оешмаларында эшләүче
хезмәткәрләргә - яшь белгечләргә акчалата
түләүләр бирү тәртибенә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр - яшь белгечләр реестры

| № т/б | Оешманың кыскача исеме | Хезмәткәрнең - яшь белгечнең Ф.И.А.и. | Белеме | Белеме буенча белгечлеге | Били торган вазыйфасы | Оешмада эшли башлау датасы | Ставкадагы эш күләме | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | |
| 4 | | | | | | | | |